РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

№ 31
РЕШЕНИЕ

16.12.2024
КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Саба муниципаль районы Килдебәк ~~эче~~ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында 23.10.2024 елгы №23 карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 нчы октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

**1.** 1. Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендә кабул ителгән 34 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында» карары белән расланган Килдебәк авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Татарстан Республикасы,Саба муниципаль районы, Килдебәк авылы, Кооперативная ур., 20А йорт;

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Туктар авылы, Советская ур., 35А йорт;

-Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Мәртен авылы, Киров ур., 1 йорт.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәавыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве өчен әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәавыл җирлеге Башлыгы Н.Н.Заһидуллинга йөкләргә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин

РАСЛАРГА
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Килдебәк авыл
җирлеге Советының 2024 елның
16 декабрендә кабул ителгән №31
Карары белән расларга

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Килдебәк җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр
һәм өстәмәләр

**1.** 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:
"21) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

**2.** 5 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

**3.** 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.;

**4.** 34 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;

**5.** 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:: «12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

**6.** 50 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- стратегик планлаштыру документларын эшләү һәм гамәлгә ашыру; стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору; стратегик планлаштыру өлкәсендә җирлек Советы вәкаләтләренә кертелмәгән башка вәкаләтләр.»;

**7.** 50 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:
«- шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

**8.** 50 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасының өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

**9.** 59 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

**10.** 73 статьяның 9 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - хокукый актның тулы текстын элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән Вакытлы матбугат басмасында - «Саба таңнары» (Саба таңнары) район газетасында бастырып чыгару (ПИ ММЧны теркәү турында ТУ16-01686 номерлы таныклык бирелгән 10.10.2019 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү). Муниципаль хокукый акт басылып чыкканда басма массакүләм мәгълүмат чарасының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.;»

**11.** 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты түбәндәге адреста эшли: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Килдебәк авылы, Кооперативная урамы, 20А йорт (Килдебәк авыдл китапханәсе).».